Проект

«2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладе хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы
КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе А.М. Терентьев тарафыннан тәкъдим ителгән «2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» докладны тыңлап, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. «2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладын игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. Җәмгыятьне берләштерү буенча гражданнар башлангычларына актив ярдәм итү, Татарстан Республикасы алдында торучы бурычларны хәл итүдә коммерциягә карамаган оешмаларның, башка граждан җәмгыяте институтларының ролен арттыру эшен дәвам итәргә.

2.2. Дәүләт тарафыннан кабул ителә торган социаль һәм икътисадый ярдәм чараларын мәгълүмати тәэмин итү өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре белән хезмәттәшлекне көчәйтергә.

2.3. Традицион гаилә кыйммәтләрен саклау һәм яшь буынга патриотик тәрбия бирү эшендә актив катнашырга.

2.4. 2026 елда Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутатларын сайлауларны әзерләү һәм үткәрү чорында иҗтимагый контрольне көчәйтергә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына «2025 елда Татарстан Республикасында

граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладындагы тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, республика башкарма хакимият органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренә коммерциягә карамаган оешмаларга илкүләм проектларны гамәлгә ашыру кысаларындагы региональ проектларда аларны башкаручылар буларак катнашуларына ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгына массакүләм мәгълүмат чараларында Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше мәсьәләләренә багышланган материаллар урнаштыруга аерым игътибар бирүне тәкъдим итәргә.

6. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына «2025 елда Татарстан Республикасында граждан җәмгыяте институтларының торышы һәм үсеше турында» Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы докладындагы Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру мәсьәләләрен карарга һәм алар буенча кирәкле чаралар күрергә.

7. Әлеге карарның 2 – 5 пунктларын үтәү барышы турында мәгълүматны 2027 елның 15 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитетына җибәрергә.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтыновка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы